**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 июль № 502

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне оештыру мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне оештыру мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 26 сентябрь, 703 нче; 2009 ел, 8 май, 284 нче; 2009 ел, 31 август, 595 нче; 2010 ел, 2 апрель, 227 нче; 2010 ел, 28 июнь, 520 нче; 2011 ел, 22 февраль, 146 нчы; 2012 ел, 23 июнь, 547 нче; 2012 ел, 28 декабрь, 1163 нче; 2014 ел, 8 май, 308 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 нче пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

4 нче пункттагы «Татарстан Республикасының Дәүләт сатып алулары идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт

комитетына» сүзләренә, «учреждениесе» сүзләрен «унитар предприятиесе» сүзләренә алыштырырга;

карарга түбәндәге эчтәлекле яңа $4^1$ нче пункт өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы заказчылары кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге буенча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләүне һәм алар өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне оештыру тәртибе нигезендә сайлыйлар, дип билгеләргә.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлегендәге 16 нчы пункт үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карар белән расланган электрон документларны этаплап формалаштыру һәм үзәкләштерелгән дәүләт сатып алуларының «Электрон кибет» автоматлаштырылган системасына кертү графигы үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\502.docx